КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 февраль г.Казань № 143

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 май, 385 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1356 нчы; 2022 ел, 25 апрель, 393 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1468 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «2022 елда Россия Федерациясенең кайбер субъектларында Карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасының бертип моделен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 29 декабрендәге 929 номерлы боерыгы белән расланган» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «2023 елда Россия Федерациясенең кайбер субъектларында Карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасының бертип моделен гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 781 номерлы боерыгы белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

икенче абзацта «2021 – 2024 елларда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2021 – 2024 елларда» сүзләрен «2023 елда» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карар белән расланган «2021 – 2024 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын финанс белән тәэмин итү кагыйдәләрен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның 1 пунктындагы алтынчы – тугызынчы абзацы гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 март, 198 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 февраль, 143 нче
карары редакциясендә)

## 2023 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын финанс белән тәэмин итү кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын гамәлгә ашырганда «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында федераль бюджеттан өстәп финанслана торган акчаны тоту механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү әлеге чыгым йөкләмәләрен өстәп финанслау максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия (алга таба – федераль бюджеттан субсидия) һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бу Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Федераль бюджеттан бирелә торган субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм иң чик финанслау күләмнәре турында Казначылыктан мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә Министрлыкка, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан иң чик финанслау күләмнәре җиткерелгәч, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре

лимитлары чикләрендә иң чик финанслау күләмнәрен җиткерә.

6. Министрлык бу Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән акча исәбеннән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

«Сиделка» хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирүне;

өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында озак вакыт карауның социаль пакеты кысаларында чит кеше каравына мохтаҗ гражданга түләүсез социаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләренә субсидия бирүне («карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү).

7. Министрлык «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына электрон документ формасында түбәндәге хисапларны тапшыра:

федераль бюджеттан субсидия алынган кварталдан соң килә торган айның 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, өстәп финанслау максаты белән федераль бюджеттан субсидия бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында;

федераль бюджеттан бирелә торган субсидияне файдалану нәтиҗәсенә ирешү датасы билгеләнгән хисап елыннан соң килә торган айның бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, федераль бюджеттан бирелә торган субсидияне файдалану нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында.

8. Агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр Татарстан Республикасы тарафыннан федераль бюджеттан субсидия бирелгән елның 31 декабренә карата федераль бюджеттан бирелгән субсидияне файдалану нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган һәм федераль бюджеттан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елда мондый күрсәткечләргә ирешү турында хисаплылык бирелә торган беренче датага кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, федераль бюджеттан бирелә торган субсидия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары белән расланган «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасының $8^4$ кушымтасында бирелгән Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен өстәп финанслау максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидия бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә федераль бюджеттан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

9. Министрлык, комплекслы үзәкләр тапшырыла торган хисап белешмәсенең дөрес булмавы һәм акчаның максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

10. Акчаны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 март, 198 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 февраль, 143 нче
карары редакциясендә)

# 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турында нигезләмә

1. Бу Нигезләмә 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең (алга таба – хезмәткәрләр) хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләрен билгели.

2. Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә таянып, түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнә:

хезмәткәрләрнең окладлы (вазыйфаи окладлы) 15 279,0 сум күләмендә билгеләнә;

хезмәткәрнең хезмәт хакы ставкасы өчен хезмәт күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар санының тәкъдим ителә торган нормативы социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының карауга мохтаҗлык дәрәҗәсенә бәйле һәм түбәндәгечә тәшкил итә:

алты кеше – чит кеше каравына мохтаҗлык буенча беренче дәрәҗә;

өч кеше – чит кеше каравына мохтаҗлык буенча икенче дәрәҗә;

ике кеше – чит кеше каравына мохтаҗлык буенча өченче дәрәҗә;

хезмәткәрләргә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә акча окладның (вазыйфаи окладның) 150 проценты күләмендә билгеләнә.

---